**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Порядка взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственных им государственных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями

В соответствии с Федеральным законом от 11 августа 1995 года № 135-ФЗ «О благотворительной деятельности и добровольчестве (волонтерстве)», постановлением Правительства Российской Федерации от 28 ноября 2018 года № 1425 «Об утверждении общих требований к порядку взаимодействия федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти субъектов Российской Федерации, органов местного самоуправления, подведомственных им государственных и муниципальных учреждений, иных организаций с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности и добровольческими (волонтерскими) организациями и перечня видов деятельности, в отношении которых федеральными органами исполнительной власти, органами исполнительной власти субъектов Российской Федерации, органами местного самоуправления утверждается порядок взаимодействия государственных и муниципальных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями», Законом Республики Татарстан от 30 июня 2018 года № 48-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере добровольчества (волонтерства) и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Утвердить прилагаемый Порядок взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственных им государственных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями (далее – Порядок).

2. Министерству здравоохранения Республики Татарстан, Министерству труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан утвердить порядок взаимодействия подведомственных государственных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями

по соответствующему компетенции виду деятельности, установленному постановлением Правительства Российской Федерации от 28 ноября 2018 года № 1425 «Об утверждении общих требований к порядку взаимодействия федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти субъектов Российской Федерации, органов местного самоуправления, подведомственных им государственных и муниципальных учреждений, иных организаций с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности и добровольческими (волонтерскими) организациями и перечня видов деятельности, в отношении которых федеральными органами исполнительной власти, органами исполнительной власти субъектов Российской Федерации, органами местного самоуправления утверждается порядок взаимодействия государственных и муниципальных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями», с учетом положений Порядка, утвержденного настоящим Указом.

3. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
16 апреля 2019 года
№ УП-223

Утвержден
Указом Президента
Республики Татарстан

от «16» апреля 2019 года

№ УП-223

**Порядок**
**взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственных им государственных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями**

1. Настоящий Порядок разработан в соответствии с Федеральным законом от 11 августа 1995 года № 135-ФЗ «О благотворительной деятельности и добровольчестве (волонтерстве)» (далее – Федеральный закон), постановлением Правительства Российской Федерации от 28 ноября 2018 года № 1425 «Об утверждении общих требований к порядку взаимодействия федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти субъектов Российской Федерации, органов местного самоуправления, подведомственных им государственных и муниципальных учреждений, иных организаций с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности и добровольческими (волонтерскими) организациями и перечня видов деятельности, в отношении которых федеральными органами исполнительной власти, органами исполнительной власти субъектов Российской Федерации, органами местного самоуправления утверждается порядок взаимодействия государственных и муниципальных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями», Законом Республики Татарстан от 30 июня 2018 года № 48-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере добровольчества (волонтерства) и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан» в целях организации взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственных им государственных учреждений с организаторами добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями.

2. Организатор добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческая (волонтерская) организация в целях осуществления взаимодействия направляют органам исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственным им государственным учреждениям почтовым отправлением с описью вложения или в форме электронного документа

через информационно-телекоммуникационную сеть «Интернет» предложение о намерении взаимодействовать в части организации добровольческой (волонтерской) деятельности (далее – предложение), которое содержит следующую информацию:

а) фамилия, имя, отчество (при наличии), если организатором добровольческой (волонтерской) деятельности является физическое лицо;

б) фамилия, имя, отчество (при наличии) и контакты руководителя организации или ее представителя (телефон, электронная почта, адрес), если организатором добровольческой (волонтерской) деятельности является юридическое лицо;

в) государственный регистрационный номер, содержащийся в Едином государственном реестре юридических лиц;

г) сведения об адресе официального сайта или официальной страницы в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (при наличии);

д) идентификационный номер, содержащийся в единой информационной системе в сфере развития добровольчества (волонтерства) (при наличии);

е) перечень предлагаемых к осуществлению видов работ (услуг), осуществляемых добровольцами (волонтерами) в целях, предусмотренных пунктом 1 статьи 2 Федерального закона, с описанием условий их оказания, в том числе возможных сроков и объемов работ (оказания услуг), уровня подготовки, компетенции, уровня образования и профессиональных навыков добровольцев (волонтеров), наличия опыта соответствующей деятельности организатора добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческой (волонтерской) организации и иных требований, установленных законодательством Российской Федерации.

3. Орган исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственное ему государственное учреждение по результатам рассмотрения предложения в срок, не превышающий 10 рабочих дней со дня его поступления, принимают одно из следующих решений:

о принятии предложения;

об отказе в принятии предложения с указанием причин, послуживших основанием для принятия такого решения.

Срок рассмотрения предложения может быть увеличен на 10 рабочих дней в случае, если необходимо запросить дополнительную информацию у организатора добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческой (волонтерской) организации.

4. Орган исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственное ему государственное учреждение информируют организатора добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческую (волонтерскую) организацию о принятом решении почтовым отправлением с описью вложения или в форме электронного документа через информационно-телекоммуникационную сеть «Интернет» в соответствии со способом направления предложения в срок,

не превышающий семи рабочих дней со дня истечения срока рассмотрения предложения.

5. В случае принятия предложения орган исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственное ему государственное учреждение информируют организатора добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческую (волонтерскую) организацию об условиях осуществления добровольческой (волонтерской) деятельности:

а) об ограничениях и о рисках, в том числе вредных или опасных производственных факторах, связанных с осуществлением добровольческой (волонтерской) деятельности;

б) о правовых нормах, регламентирующих работу органа исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственных ему государственных учреждений;

в) о необходимых режимных требованиях, правилах техники безопасности и других правилах, соблюдение которых требуется при осуществлении добровольческой (волонтерской) деятельности;

г) о порядке и сроках рассмотрения (урегулирования) разногласий, возникающих в ходе взаимодействия сторон;

д) о сроке осуществления добровольческой (волонтерской) деятельности и основаниях для досрочного прекращения ее осуществления;

е) об иных условиях осуществления добровольческой (волонтерской) деятельности.

6. Организатор добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческая (волонтерская) организация в случае отказа государственного учреждения, подведомственного органу исполнительной власти Республики Татарстан, принять предложение вправе направить органу исполнительной власти Республики Татарстан, являющемуся учредителем государственного учреждения, аналогичное предложение, которое рассматривается в соответствии с пунктами 2–4 настоящего Порядка.

7. Взаимодействие органов исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственных им государственных учреждений с организатором добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческими (волонтерскими) организациями осуществляется на основании соглашения о взаимодействии (далее – соглашение), за исключением случаев, определенных сторонами.

8. Соглашение заключается с организатором добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческой (волонтерской) организацией в случае принятия органом исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственным ему государственным учреждением предложения и предусматривает:

а) перечень видов работ (услуг), осуществляемых организатором добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческой (волонтерской) организацией в целях, указанных в пункте 1 статьи 2 Федерального закона;

б) условия осуществления добровольческой (волонтерской) деятельности;

в) сведения об уполномоченных представителях, ответственных за взаимодействие со стороны организатора добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческой (волонтерской) организации и со стороны органов исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственных им государственных учреждений, для оперативного решения вопросов, возникающих при взаимодействии;

г) порядок, в соответствии с которым орган исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственное ему государственное учреждение информируют организатора добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческую (волонтерскую) организацию о потребности в привлечении добровольцев (волонтеров);

д) возможность предоставления органом исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственным ему государственным учреждением мер поддержки, предусмотренных Федеральным законом, помещений и необходимого оборудования;

е) возможность учета деятельности добровольцев (волонтеров) в единой информационной системе в сфере развития добровольчества (волонтерства);

ж) обязанность организатора добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческой (волонтерской) организации информировать добровольцев (волонтеров) о рисках, связанных с осуществлением добровольческой (волонтерской) деятельности (при наличии), правовых нормах, регламентирующих работу органа исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственного ему государственного учреждения;

з) обязанность организатора добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческой (волонтерской) организации информировать добровольцев (волонтеров) о необходимости уведомления о перенесенных и выявленных у них инфекционных заболеваниях, препятствующих осуществлению добровольческой (волонтерской) деятельности;

и) иные положения, не противоречащие законодательству Российской Федерации.

9. Урегулирование разногласий, возникающих в процессе согласования проекта соглашения, осуществляется путем переговоров между сторонами соглашения.

10. Срок заключения соглашения с органами исполнительной власти Республики Татарстан, подведомственными им государственными учреждениями не может превышать 14 рабочих дней со дня получения организатором добровольческой (волонтерской) деятельности, добровольческой (волонтерской) организацией информации о принятом предложении.

---

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, алар карамагындагы дәүләт учреждениеләренең ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыяри ярдәм хәрәкәте (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, алар карамагындагы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләренең, башка оешмаларның ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек тәртибенә гомуми таләпләрне һәм аларга карата федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе расланган эшчәнлек төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 1425 номерлы карары, «Ихтыяри хәрәкәт (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлеше нигезендә **карар бирәм**:

1. Указга теркәп бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, алар карамагындагы дәүләт учреждениеләренең ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына алар карамагындагы дәүләт учреждениеләренең компетенцияләренә туры килә торган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең

«Федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, аларның карамагындагы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләренең, башка оешмаларның ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек тәртибенә гомуми таләпләрне һәм аларга карата Федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе расланган эшчәнлек төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 1425 номерлы карары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек төре буенча ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен, әлеге Указ белән расланган Тәртип нигезләмәләрен исәпкә алып, расларга.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 16 апрель
№ ПУ-223

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның «16» апрелендәге
ПУ-223 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, алар карамагындагы дәүләт учреждениеләренең ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыяри ярдәм хәрәкәте (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, алар карамагындагы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләренең, башка оешмаларның ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек тәртибенә гомуми таләпләрне һәм аларга карата федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе расланган эшчәнлек төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 1425 номерлы карары, «Ихтыярилык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, алар карамагындагы дәүләт учреждениеләренең ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында эшләнде.

2. Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасы үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максатында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына, аларның карамагындагы дәүләт учреждениеләренә почта аша, теркәп җибәрелә торган документларның исемлеге белән, яки электрон документ

рәвешендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыру буенча үзара хезмәттәшлек алып бару нияте турында тәкъдим (алга таба – тәкъдим) җибәрә, анда түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:

а) әгәр ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы физик зат булса, аның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда);

б) әгәр ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы юридик зат булса, оешма җитәкчесе яки аның вәкиле фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда) һәм контактлары (телефоны, электрон почтасы, адресы);

в) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы дәүләт теркәве номеры;

г) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайт яки рәсми сәхифә адресы турында белешмәләр (булганда);

д) ихтыяри ярдәмне (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасындагы идентификацияләү номеры (булганда);

е) эш төрләрен башкару шартларын, шул исәптән эшләрнең (хезмәт күрсәтүләрнең) мөмкин булган сроклары һәм күләмнәрен, әзерлек дәрәҗәсен, компетенциясен, ихтыяри ярдәм күрсәтүчеләрнең (волонтерларның) белем һәм һөнәри күнекмәләре дәрәҗәсен, ихтыяри ярдәм эшчәнлеген оештыручының, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасының тиешле эшчәнлек тәҗрибәсе булуын һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бүтән таләпләрне тасвирлап, Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктта каралган максатларда ихтыяри ярдәм белән шөгыльләнүче затлар (волонтерлар) гамәлгә ашыра торган, гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган эшләр (хезмәт күрсәтүләр) исемлеге.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, аның карамагындагы дәүләт учреждениесе тәкъдим алынган көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, аны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

тәкъдимне кабул итү турында;

мондый карар чыгаруга нигез булган сәбәпләрне күрсәтеп, тәкъдимне кабул итүдән баш тарту турында.

Тәкъдимне карап тикшерү срогы, ихтыяри ярдәм эшчәнлеген оештыручыдан, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасыннан өстәмә мәгълүмат соратып алырга кирәк булган очракта, 10 эш көненә озайтылырга мөмкин.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, аның карамагындагы дәүләт учреждениесе ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыга, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасына почта аша, теркәп җибәрелә торган документларның исемлеге белән, яки электрон документ рәвешендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша тәкъдим җибәрү ысулы нигезендә тәкъдимне карап тикшерү срогы узган көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

5. Тәкъдим кабул ителгән очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, аның карамагындагы дәүләт учреждениесе ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыга, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасына ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыру шартлары турында хәбәр итә:

а) чикләүләр турында һәм куркынычлар хакында, шул исәптән ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле зарарлы яки куркыныч җитештерү факторлары турында;

б) дәүләт хакимияте органының, аның карамагындагы дәүләт учреждениеләренең эшен регламентлаштыручы хокукый нормалар турында;

в) куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашырганда аларны үтәү таләп ителә торган тиешле режим таләпләре, техник куркынычсызлык кагыйдәләре һәм башка кагыйдәләр турында;

г) яклар хезмәттәшлеге барышында барлыкка килә торган каршылыкларны карап тикшерү (җайга салу) тәртибе һәм сроклары турында;

д) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру вакыты һәм аны гамәлгә ашыруны вакытыннан алда туктатуга нигезләр турында;

е) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыруның бүтән шартлары турында.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының карамагындагы учреждение тәкъдимне кабул итүдән баш тарткан очракта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасы әлеге учреждениене гамәлгә куючы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына әлеге Тәртипнең 2 – 3 пунктлары нигезендә карап тикшерелә торган шундый ук тәкъдимне җибәрергә хокуклы.

7. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, аларның карамагындагы дәүләт учреждениеләренең ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге, яклар тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш, үзара хезмәттәшлек турында килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Килешү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, аның карамагындагы дәүләт учреждениесе тарафыннан тәкъдимен хуплау турында карар кабул ителгән очракта ихтыяри ярдәм эшчәнлеген оештыручы, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасы белән төзелә һәм анда түбәндәгеләр күздә тотыла:

а) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасы тарафыннан Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктта күрсәтелгән максатларда гамәлгә ашырыла торган эшләр (хезмәт күрсәтүләр) төрләре исемлеге;

б) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары;

в) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасы ягыннан һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, аларның карамагындагы дәүләт учреждениеләре ягыннан үзара хезмәттәшлек вакытында барлыкка килә торган мәсьәләләрне оператив рәвештә хәл итү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләр турында мәгълүматлар;

г) анын нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, аларның карамагындагы дәүләт учреждениеләре ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыны, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасын ихтыяри ярдәм белән шөгыльләнүче затларны җәлеп итү ихтыяҗы турында хәбәр иткән тәртип;

д) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, аларның карамагындагы дәүләт учреждениеләре тарафыннан Федераль законда каралган ярдәм чаралары, биналар һәм кирәкле җиһазлар бирү мөмкинлеге;

е) ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) эшчәнлеген ихтыяри ярдәм хәрәкәтен (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында исәпкә алу мөмкинлеге;

ж) ихтыяри ярдәм хәрәкәтен (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасының бурычы федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы билгели торган таләпләрне исәпкә алып, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле куркыныч турында (булган очракта), ихтыяри ярдәм белән шөгыльләнүчеләргә хәбәр итү;

з) ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасының бурычы ихтыяри ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнүчеләргә (волонтерларга) алар кичергән һәм аларда ачыкланган, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыруга каршылык тудыра торган йогышлы авырулар турында белдерү кирәклеге хакында хәбәр итү, шулай ук күрсәтелгән мәгълүматны эштә файдалану.

9. Уртак эшчәнлек турында килешүне килештерү барышында каршылыклар килеп чыкканда яклар, кирәк булган очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында төзелгән киңәшмә органнар, Татарстан Республикасында төзелгән бүтән киңәшмә һәм ярдәмче органнар вәкилләрен җәлеп итеп, әлеге каршылыкларны бергәләп карап тикшерергә тиеш.

10. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, аларның карамагындагы дәүләт учреждениеләре белән килешү төзү срогы ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) оешмасы тәкъдимне хуплау турында карар алган көннән алып 14 эш көненнән дә артмаска тиеш.